СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**К А Р А Р Ы**

**«_24_» _апрель_ 2018 ел** **№ _166_**

**Арча район Советының 2013 елның 12 октябрендәге 231 номерлы карары белән расланган “Арча муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (Арча район Советының 2015 елның 26 октябрендәге 10 номерлы карары редакциясендә)**

“Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында” 2017 елның 28 мартындагы 48-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Арча районы прокуроры протесты нигезендә Арча муниципаль районы Советы карар бирде:

1. «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 15 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Россия Федерациясе Президенты юлламасы нигезләмәләре;

Россия Федерациясенең бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләре (Россия Федерациясе субъектлары бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре, муниципаль берәмлекләрнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре);

социаль-икътисадый үсеш фаразы;

озак сроклы чорга бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразы проекты);

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет-финанс мәсьәләләре буенча Арча район Советының даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г. Нуриев